**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“19” ноябрь 2021 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Иске Җогып торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылы территориясендә 2022 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән,тавыш бирү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Иске Җогып авылында скважина ремонтлау (материаллар алу, торбаларын алыштыру, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
2. Иске Югуп авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү;
3. Туң җирне казу өчен бензин белән эшли торган җайланма сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Иске Җогып авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Яңа Шашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
Новошашинского сельского поселения
Яңа Шашы авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000765
ОГРН 1021606356110